Ул һәр нәрсәгә кодрәте җитүче. Раббым бу көннең вә аннан соң буласының яхшылыгын Синнән сорыйм. Раббым бу көннең һәм аннан соңрагының яманлыгыннан Сиңа сыенам. Раббым, Сиңа Уттагы газаптан вә кабер газабыннан сыенам".

***Кичен:***

"أَمْسَيْنَا وَأَمْسَى الْمُلْكُ لِلَّهِ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ، رَبِّ أَسْأَلُكَ خَيْرَ مَا فِي هَذِهِ اللَّيْلَةِ وَخَيْرَ مَا بَعْدَهَا وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا فِي هَذِهِ اللَّيْلَةِ وَشَرِّ مَا بَعْدَهَا، رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْكَسَلِ، وَسُوءِ الْكِبَرِ، رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابٍ فِي النَّارِ وَعَذَابٍ فِي الْقَبْرِ"

"Аллаһ тәгалә өчен безнең берлә бөтен милек кичне каршылады, Аллаһ тәгаләгә барча мактау, Аллаһтан кала гыйбадәткә лаек зат юк, Ул бер үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча милек, Аңа гына барлык мактау, вә Ул һәр нәрсәгә кодрәте җитүче. Раббым бу төннең вә аннан соң буласының яхшылыгын Синнән сорыйм. Раббым бу төннең һәм аннан соңрагының яманлыгыннан Сиңа сыенам. Раббым, Сиңа Уттагы газаптан вә кабер газабыннан сыенам".

***Кичен:***

"اَللَّهُمَّ بِكَ أَمْسَيْنَا وَبِكَ أَصْبَحْنَا وَبِكَ نَحْيَا وَبِكَ نَمُوتُ وَإِلَيْكَ الْمَصِيرُ"

"И Аллаһ, Синең белән кичкә кердек вә синең берлә иртәне каршыладык, Синең белән яшибез һәм Синең илә үләбез. Вә Синең каршыңа кире кайтуыбыз".

***Кайда булса яки кемдә булса бер җирдә тукталса һәм кичен өчәр кат*** *(урыннан кузгалып киткәнче һичнәрсә аңа зыян китермәс)*:

"أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ"

"Мәхлукларның яманлыгыннан Аллаһ тәгаләнең камил сүзләре илә сыенам".



## ФАРЫЗ НАМАЗЫННАН СОҢ ӘЙТЕЛӘ ТОРГАН ЗИКЕРЛӘР

"Аллаһтан ярлыкауны сорыйм" (3 тапкыр) "أَسْتَغْفِرُ اللهَ"

"اَللَّهُمَّ أَنْتَ السَّلاَمُ، وَمِنْكَ السَّلاَمُ، تَبَارَكْتَ يَا ذَا الْجَلاَلِ وَالإِكْرَامِ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ، اَللَّهُمَّ لاَ مَانِعَ لِمَا أَعْطَيْتَ وَلاَ مُعْطِيَ لِمَا مَنَعْتَ وَلاَ يَنْفَعُ ذَا الْجَدِّ مِنْكَ الْجَدُّ"

"И Аллаһ, Син барча кимчелекләрдән ерак вә имин, һәм тынычлык, иминлек, хәвефсезлек, вә барча иминлек Синнән (генә), югарыланып изге булдың, и Күркәмлек вә Хөрмәтләү иясе. Аллаһтан кала гыйбадәткә лаек зат юк, Ул бер үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча милек, Аңа гына барлык мактау, вә Ул бар нәрсәгә кодрәте җитүче. И Аллаһ, Син биргәнгә тыючы юк, Син тыйганны бирүче юк вә мәртәбә иясенә дә мәртәбәсеннән файда юк. Мәртәбә Синнән генә".

"لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ. لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، وَلاَ نَعْبُدُ إِلاَّ إِيَّاهُ، لَهُ النِّعْمَةُ وَلَهُ الْفَضْلُ وَلَهُ الثَّنَاءُ الْحَسَنُ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ وَلَوْ كَرِهَ الْكَافِرُونَ"

"Аллаһтан кала гыйбадәткә лаек зат юк, Ул бер үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча милек, Аңа гына барлык мактау, вә Ул бар нәрсәгә кодрәте җитүче. Аллаһтан кала көч-куәт юк, Аллаһтан кала гыйбадәткә лаек зат юк, Аннан башка һичкемгә гыйбадәт кылмыйбыз, Аңа нигъмәт, Аңа дәрәҗә һәм күркәм мактау, Аллаһ газзә вә җәлләдән башка гыйбадәткә лаек һич бер зат юк, Аңа динне ихлас белән үтибез, гәрчә кяферләр сөймәсәләр дә".



"Аллаһ кимчелекләрдән пакь" (33 кат) "سُبْحَانَ اللهِ"

"Аллаһка барча мактау" (33 кат) "اَلْحَمْدُ لِلَّهِ"

"Аллаһ һәр нәрсәдән олуграк" (33 кат) "اَللهُ أَكْبَرُ"

***йөзенче мәртәбә***:

"لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ"

"Аллаһтан кала гыйбадәткә лаек зат юк, Ул бер үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча милек, Аңа гына барлык мактау, вә Ул бар нәрсәгә кодрәте җитүче ".

"*Һәрбер намаздан соң шуны әйтсә, аның гөнаһлары диңгез күбеге хәтле күп булса да, кичерелер*".

***«Аятел-Көрсине» укый*** *(«Бакара» сүрәсе, 255 аять)*:

﴿اَللَّهُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ ...﴾ سورة البقرة ٢٥٥

*"Һәр намаздан соң бу аятьне әйтүченең җәннәткә керүенә үлемнән башка һичбер киртә булмас".*

***Һәрбер намаздан соң берәр кат, әмма иртәнге намаз белән ахшамнан соң өчәр мәртәбә әйтә:***

﴿قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ ...﴾ ﴿قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ ...﴾ ﴿قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ ...﴾

***Ахшам белән иртәнге намаздан соң унар кат әйтә:***

"لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ يُحْيِي وَيُمِيتُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ"

"Аллаһтан кала гыйбадәткә лаек зат юк, Ул бер үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча милек, Аңа гына барлык мактау, яшәтә һәм вафат кыла вә Ул бар нәрсәгә кодрәте җитүче".



بسم الله الرحمن الرحيم

Аллаһ тәгалә әйтте:

﴿فَاذْكُرُونِي أَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوا لِي وَلاَ تَكْفُرُونِ﴾ سورة البقرة ١٥٢

**«Мине искә алыгыз, сезне истә тотармын, Миңа шөкрана кылыгыз вә Миңа карышмагыз».**

**БҮЛӘК**

# МӨСЕЛМАННЫҢ КӨНДӘЛЕК ЗИКЕРЛӘРЕ



**أذكار المسلم اليومية باللغة التترية**

# ИРТӘ ВӘ КИЧ ЗИКЕРЛӘРЕ

***Иртән, кичен һәм йокы алдыннан Аятел-Көрсине уку*** *(шайтаннан саклый):*

﴿اللَّهُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لاَ تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلاَ نَوْمٌ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الأَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلاَّ بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْـــدِيهِمْ وَمَـــا خَلْفَهُـــمْ وَلاَ يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلاَّ بِمَا شَاءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضَ وَلاَ يَئُـــودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ﴾ سورة البقرة ٢٥٥

**«Аллаһ, Аннан кала һич гыйбадәткә лаек зат юк, Тере, бар нәрсәне саклап, тәртиптә тотып Торгызучы, Аны йокымсырау да йокы да алмый; Күкләр белән Җирдә булганнарның милке Аңа гына. Кем Аның рөхсәтеннән башка Аның каршында шәфәгатьче булыр? (Ул мәхлукларының) алдларында вә артларында ни булганын белә вә алар Аның гыйлеменнән бер ни дә белә алмыйлар, мәгәр Ул теләгәнне генә. Аның Көрсие Күкләр белән Җирдән киң булды, вә аларны саклау Аңа һич кыенлык китермәс. Вә Ул Югары, Бөек».** *(«Бакара» сүрәсе, 255 аять)*

***Һәрберсен иртән вә кичен өчәр мәртәбә:***

بسم الله الرحمن الرحيم

﴿قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ(١) اللَّهُ الصَّمَدُ(٢) لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ(٣) وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ(٤)﴾

Мәрхәмәтле вә Шәфкатьле Аллаһ исеме илә

**❬Әйт: «Ул — Аллаһ бер. Аллаһ һичнәрсәгә мохтаҗ түгел вә башкалар һәммәсе Аңа мохтаҗ. Ул тудырмады вә тумады. Һичкем Аңа тиңдәш булмады»❭.**



بسم الله الرحمن الرحيم

﴿قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ(١) مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ(٢) وَمِنْ شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ(٣) وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ(٤) وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ(٥)﴾

Мәрхәмәтле вә Шәфкатьле Аллаһ исеме илә

**❬Әйт: «Барча мәхлукларның яманлыгыннан, төнге караңгылык төшкәндә булган яманлыктан, төеннәргә өрүче сихерчеләрнең яманлыгыннан вә көнләүченең көнләгән вакыттагы яманлыгыннан таң Хуҗасына сыенам»❭.**

بسم الله الرحمن الرحيم

﴿قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ(١) مَلِكِ النَّاسِ(٢) إِلَهِ النَّاسِ(٣) مِنْ شَرِّ الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ(٤) الَّذِي يُوَسْوِسُ فِي صُدُورِ النَّاسِ(٥) مِنْ الْجِنَّةِ وَالنَّاسِ(٦)﴾

Мәрхәмәтле вә Шәфкатьле Аллаһ исеме илә

**❬Әйт: «Җеннәрдән вә кешеләрдән булучы кешеләрнең йөрәкләрендә вәсвәсә кылучы (Аллаһ зикереннән) качучының яманлыгыннан кешеләр Хуҗасына, Патшасына вә Илаһына сыенам»❭.**

***Бер тапкыр иртән вә кичен*** *(кичен зикерне ихлас әйтүче төнлә вафат булса, җәннәткә керер):*

"اَللَّهُمَّ أَنْتَ رَبِّي لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ خَلَقْتَنِي وَأَنَا عَبْدُكَ وَأَنَا عَلَى عَهْـــدِكَ وَوَعْـــدِكَ مَـــا اسْتَطَعْتُ أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا صَنَعْتُ أَبُوءُ لَكَ بِنِعْمَتِكَ عَلَيَّ وَأَبُوءُ لَكَ بِذَنْبِي فَاغْفِرْ لِي فَإِنَّهُ لاَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلاَّ أَنْتَ"

"И Аллаһ, Син минем Хуҗам, Мине яраттың вә мин Синең колың, булдыра алганымча мин Синең антыңда һәм вәгъдәңдә (калам), кылганнарымның яманлыгыннан Сиңа сыенам; миңа булган нигъмәтең илә Сиңа кайтам, вә гөнаһым белән Сиңа кайтам, миңа (аны) ярлыкасаң



иде, чөнки Синнән башка гөнаһларны ярлыкаучы һичкем юк".

***Бер тапкыр иртән вә кичен:***

"اَللَّهُمَّ عَالِمَ الْغَيْبِ وَالشَّهَادَةِ فَاطِرَ السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضِ، رَبَّ كُلِّ شَـــيْءٍ وَمَلِيكَـــهُ، أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ، أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ نَفْسِي، وَمِنْ شَرِّ الشَّيْطَانِ وَشِـــرْكِهِ، وَأَنْ أَقْتَرِفَ عَلَى نَفْسِي سُوءًا، أَوْ أَجُرَّهُ إِلَى مُسْلِمٍ"

"И Аллаһ, яшерен вә күзәтелүче гыйлемне Белүче, Күкләр белән Җирне Яратучы, һәрнәрсәнең Хуҗасы һәм Патшасы, Синнән кала һич тәңре юк диеп шәһадәт кылам. Җанымның яманлыгыннан, шайтанның явызлыгы белән ширегеннән (бөтен эшләрдә катнашуыннан, Аллаһ тәгаләгә тиңдәш тануга илтүеннән), үземә начарлык кылудан яки берәр мөселманга аны әйләүдән, тагудан Сиңа сыенам".

***Иртән вә кичен өчәр кат:***

"رَضِيتُ بِاللهِ رَباً، وَبِالإِسْلاَمِ دِيناً، وَبِمُحَمَّدٍ ﷺ نَبِياً"

"Аллаһны Раббым диеп, Исламны динем диеп һәм Мөхәммәдне ﷺ Пәйгамбәр диеп разый булдым".

***Иртән вә кичен өчәр кат:***

"بِسْمِ اللَّهِ الَّذِي لاَ يَضُرُّ مَعَ اسْمِهِ شَيْءٌ فِي الأَرْضِ وَلاَ فِي السَّمَاءِ وَهُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ"

"Аллаһ исеме илә (башлыйм), Җирдә вә Күктә булган нәрсәләрдән һичбере Аның исеме илә зыян китерми. Ул Ишетүче, Белүчедер".

***Иртән:***

"اَللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ عِلْماً نَافِعاً، وَرِزْقاً طَيِّباً وَعَمَلاً مُتَقَبَّلاً"

"И Аллаһ, Синнән файдалы гыйлемне, хәләл ризыкны вә кабул булачак гамәлне сорыйм".



***Иртән:***

"اَللَّهُمَّ بِكَ أَصْبَحْنَا وَبِكَ أَمْسَيْنَا وَبِكَ نَحْيَا وَبِكَ نَمُوتُ وَإِلَيْكَ النُّشُورُ"

"И Аллаһ, Синең белән иртәне каршыладык вә синең берлә кичкә кердек, Синең белән яшибез һәм Синең илә үләбез. Вә Синең каршыңа җыелып терелүебез".

***Иртән, кичен һәм йокы алдыннан:***

"اَللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْعَفْوَ وَالْعَافِيَةَ فِي الدُّنْيَا وَالآخِرَةِ، اَللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْعَفْوَ وَالْعَافِيَةَ فِي دِينِي وَدُنْيَايَ، وَأَهْلِي وَمَالِي، اَللَّهُمَّ اسْتُرْ عَوْرَاتِي، وَآمِنْ رَوْعَاتِي، اَللَّهُمَّ احْفَظْنِي مِنْ بَيْنِ يَدَيَّ وَمِنْ خَلْفِي وَعَنْ يَمِينِي وَعَنْ شِمَالِي وَمِنْ فَوْقِي وَأَعُـــوذُ بِعَظَمَتِـــكَ أَنْ أُغْتَالَ مِنْ تَحْتِي"

"И Аллаһ, Синнән дөнья белән ахирәттә кичерүеңне вә сәламәтлекне сорыйм. И Аллаһ, Синнән динемдә, дөньямда, гаиләмдә вә малымда гафу итүеңне вә сәламәтлекне сорыйм. И Аллаһ, гаурәтләремне капла (башкаларга кимчелекләремне күрсәтмә) һәм куркудан мине имин кыл. И Аллаһ, мине алдымнан, артымнан, уң ягымнан, сул ягымнан вә өстемнән сакла. Вә түбәннән җир йотуыннан бөеклегеңә сыенам".

***Иртән:***

"أَصْبَحْنَا وَأَصْبَحَ الْمُلْكُ لِلَّهِ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَـــهُ، لَـــهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ، رَبِّ أَسْأَلُكَ خَيْرَ مَا فِي هَذَا الْيَوْمِ وَخَيْرَ مَا بَعْدَهُ وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا فِي هَذَا الْيَوْمِ وَشَرِّ مَا بَعْدَهُ، رَبِّ أَعُـــوذُ بِـــكَ مِـــنَ الْكَسَلِ، وَسُوءِ الْكِبَرِ، رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابٍ فِي النَّارِ وَعَذَابٍ فِي الْقَبْرِ"

"Аллаһ тәгалә өчен безнең берлә бөтен милек иртәне каршылады, Аллаһ тәгаләгә барча мактау, Аллаһтан кала гыйбадәткә лаек зат юк, Ул бер үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча милек. Аңа гына барлык мактау, вә